**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында электрон документ әйләнешенең бердәй ведомствоара системасы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасында электрон документ әйләнешенең бердәй ведомствоара системасы эшен камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында электрон документ әйләнешенең бердәй ведомствоара системасы турында» 2009 елның 5 февралендәге ПУ-52 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбуладагы «Электрон цифрлы имза турында» сүзләрен «Электрон имза турында» сүзләренә алмаштырырга.

б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында электрон документ әйләнешенең бердәй ведомствоара системасы эшләве кысаларында электрон имза файдаланып электрон документларны кабул итү, тапшыру һәм эшкәртү тәртибе, Татарстан Республикасында электрон документ әйләнешенең бердәй ведомствоара системасында катнашучылар составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә дип күрсәтергә.»;

в) 2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 14 май
№ ПУ-450